**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О дополнительных гарантиях обеспечения независимой антикоррупционной экспертизы проектов нормативных правовых актов органов государственной власти Республики Татарстан и учета общественного мнения при их подготовке

В целях создания дополнительных гарантий проведения независимой антикоррупционной экспертизы проектов нормативных правовых актов органов государственной власти Республики Татарстан и учета общественного мнения при их подготовке **постановляю**:

1. Создать в рамках государственной информационной системы Республики Татарстан «Официальный портал Республики Татарстан» информационный ресурс для размещения проектов нормативных правовых актов органов государственной власти Республики Татарстан в целях проведения их независимой антикоррупционной экспертизы и общественного обсуждения (http://tatarstan.ru/regulation).

2. Определить указанный в пункте 1 настоящего Указа информационный ресурс единым региональным интернет-порталом для размещения проектов нормативных правовых актов органов государственной власти Республики Татарстан в целях проведения их независимой антикоррупционной экспертизы и общественного обсуждения.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан в 90-дневный срок:

обеспечить введение в эксплуатацию и последующее функционирование информационного ресурса, указанного в пункте 1 настоящего Указа;

утвердить порядок размещения проектов нормативных правовых актов органов государственной власти Республики Татарстан на информационном ресурсе, указанном в пункте 1 настоящего Указа;

принять иные решения, обеспечивающие реализацию настоящего Указа.

4. Исполнительным органам государственной власти Республики Татарстан использовать указанный в пункте 1 настоящего Указа информационный ресурс при размещении проектов нормативных правовых

актов органов государственной власти Республики Татарстан в целях проведения их независимой антикоррупционной экспертизы и общественного обсуждения.

5. Предложить Государственному Совету Республики Татарстан, иным государственным органам Республики Татарстан использовать указанный в пункте 1 настоящего Указа информационный ресурс при размещении проектов нормативных правовых актов органов государственной власти Республики Татарстан в целях проведения их независимой антикоррупционной экспертизы и общественного обсуждения.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
29 июня 2017 года
№ УП-575

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыруны тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыруны һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны булдыру максатларында **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм җәмәгатьчелектә фикер алышу максатларында урнаштыру өчен мәгълүмат ресурсы (http://tatarstan.ru/regulation) булдырырга.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат ресурсын Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм җәмәгатьчелектә фикер алышу максатларында урнаштыру өчен бердәй төбәк интернет-порталы дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 90 көн эчендә:
әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат ресурсын кулланылышка кертүне һәм аның эшләвен тәэмин итәргә;
Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат ресурсында урнаштыру тәртибен расларга;
әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат ресурсын Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары

проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм җәмәгатьчелектә фикер алышу максатларында урнаштырганда файдаланырга.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнарына әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат ресурсын Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм җәмәгатьчелектә фикер алышу максатларында урнаштырганда файдалануны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 29 июнь
№ ПУ-575